| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«МУКМИН-КАРАТАЙСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«МӨЭМИН-КАРАТАЙ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

---

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Мөэмин-Каратай авыл җирлеге
Мөэмин-Каратай авылында гражданнар җыены
КАРАРЫ

2021 елның 20 ноябре № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мөэмин-Каратай авыл җирлегенең Мөэмин-Каратай авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 20 ноябрендә 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Мөэмин-Каратай авыл җирлегенең Мөэмин-Каратай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, 1,2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәреннән тыш, 500 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- Мөэмин-Каратай авылы Механизаторлар урам һәм Нагорная урамы буенча юллардагы чокырларны ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК».

соравы буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Халык җыены беркетмәсе нигезендә:
Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 219 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 147 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучылар бертавыштан «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирделәр.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мөэмин-Каратай авыл җирлегенең Мөэмин-Каратай авылында гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мөэмин-Каратай авыл җирлеге составына керүче Мөэмин-Каратай торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2.2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Мөэмин-Каратай авыл җирлегенең Мөэмин-Каратай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, 1,2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәреннән тыш, 500 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Мөэмин-Каратай авылы Механизаторлар урам һәм Нагорная урамы буенча юллардагы чокырларны ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мөэмин-Каратай авылы,Механизаторлар ур., 31Б адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга..

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы, Совет рәисе Ә.А.Ханнанова